ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

05.11.2020 Олы Кайбыч ав. № 480

Җирлек территорияләре өстеннән авиацион эшләр, парашюттан сикерүләр, һава судларының демонстрацион очышларын очу аппаратларының пилотсыз очуларын , тагылма аэростатлар күтәрелешенә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе һава киңлегеннән файдалануның Федераль кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 3 февралендәге 74 номерлы карары нигезендә һәм муниципаль норматив актларны гамәлдәге законнарга туры китерүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының «Эшмәкәрлек өлкәсендә муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 2019 елның 29 маендагы 255 номерлы карары белән расланган Җирлек территорияләре өстеннән авиацион эшләр, парашюттан сикерүләр, һава судларының демонстрацион очышларын очу аппаратларының пилотсыз очуларын , тагылма аэростатлар күтәрелешенә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Регламентның исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы территориясе өстендә авиация эшләрен башкаруга, парашюттан сикерүләргә, һава судноларының демонстрацион очышларына, пилотсыз һава суднолары очышларына (максималь очыш массасы 0,25 килограммнан да ким булган пилотсыз һава судноларының очышларыннан тыш), тагылма аэростатлар күтәрүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты».

1.2. Регламент тексты буенча «пилотсыз очу аппаратлары очышлары» сүзләрен «пилотсыз һава суднолары очышлары максималь очыш массасы 0,25

килограммнан да ким булган пилотсыз һава суднолары очышларыннан тыш)» сүзләре белән алмаштырырга.

1.3. 1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 6 октябрендәге 381 номерлы «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы территориясендә авиация эшләрен башкаруга, парашют сикерүләргә, һава суднoларының демонстрацион очышларына, пилотсыз очу аппаратларының очышларына рөхсәтләр бирү, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы территориясе өстендә белешмәләре аэронавигация мәгълүматы документларында басылып чыкмаган тагылма аэростатлар күтәрү, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы чикләрендә урнашкан мәйданчыкларга утырту (очып китү) буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» карарын гамәлдән чыккан дип санарга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге http:// kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча рәсми сайтында урнаштырырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның гамәлгә ашырылуын тикшереп торуны Башкарма комитет Җитәкчесенең төзелеш һәм ТКХ буенча урынбасары Ф.Ш.Әхмәтовка йөкләргә.

Җитәкче А.Н. Макаров